МИНИСТЕРСТВО НАУКИ И ВЫСШЕГО ОБРАЗОВАНИЯ
РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ
Федеральное государственное автономное образовательное учреждение
высшего образования
«Казанский (Приволжский) федеральный университет»
Институт филологии и межкультурной коммуникации

УТВЕРЖДАЮ
Проректор по образовательной
деятельности
_____________ Е.А. Турилова
«28» ____________ 2024 г.

**ПРОГРАММА ВСТУПИТЕЛЬНОГО ИСПЫТАНИЯ**
**ПО ТАТАРСКОМУ ЯЗЫКУ**
для поступающих на обучение по программам бакалавриата и программам
специалитета на базе среднего профессионального образования

**Направление подготовки:** 44.03.05 Педагогическое образование (с двумя профилями подготовки); 45.03.01 Филология.

**По программе:** Родной (татарский) язык и литература, английский язык; Прикладная филология: татарский язык и литература, журналистика.

**Форма обучения:** очная

2024

**Лист согласования программы вступительного испытания**

Разработчик(и) программы:
Зав. кафедрой общего языкознания и тюркологии _______ Р.Р. Замалетдинов

Председатель экзаменационной комиссии _________ Сагдиева Р.К.

Программа вступительного испытания обсуждена и одобрена на заседании кафедры татарского языкознания Института филологии и межкультурной коммуникации, Протокол №2 от «10» сентября 2024 г.

Решением Учебно-методической комиссии Института филологии и межкультурной коммуникации Программа вступительного испытания рекомендована к утверждению Ученым советом, Протокол №2 от «11» октября 2024 г.

Программа вступительного испытания утверждена на заседании Ученого совета Института филологии и межкультурной коммуникации, Протокол №2 от «16» октября 2024 г.

# Содержание

**Раздел 1. Вводная часть**

1.1 Цель и задачи вступительных испытаний

1.2 Общие требования к организации вступительных испытаний

1.3 Описание формы проведения вступительных испытаний

1.4 Продолжительность вступительных испытаний в минутах

1.5 Структура вступительных испытаний

**Раздел 2. Содержание программы**

**Раздел 3. Фонд оценочных средств**

3.1. Инструкция по выполнению работы

3.2. Образцы заданий вступительных испытаний

**Раздел 4. Список литературы**

## Раздел 1. Вводная часть

Настоящая программа сформирована на основе федерального государственного образовательного стандарта высшего образования по направлению подготовки 44.03.05 Педагогическое образование (с двумя профилями подготовки). Родной (татарский) язык и литература, русский язык; 45.03.01 Филология. Прикладная филология: Татарский язык и литература**,** журналистика. К сдаче вступительного испытания в бакалавриат допускаются лица, имеющие среднее образование любого уровня, подтвержденное документом о среднем образовании.

### 1.1. *Цель и задачи вступительных испытаний*

*Цель вступительного испытания:* определить готовность и возможность абитуриента освоить выбранную программу.

*Задачи вступительного испытания:*

- выявить уровень владения абитуриентом татарским языком (фонетические, лексические, грамматические навыки, речевые умения, навыки работы с текстом, умения в письменной речи на татарском языке);

- установить степень владения абитуриентом тематикой в профессиональной области на языке.

### 1.2. *Общие требования к организации вступительных испытаний*

К участию во вступительном испытании допускаются лица, подавшие документы в Университет, при наличии документа, удостоверяющего личность (в том числе паспорт гражданина Российской Федерации, удостоверяющий личность гражданина Российской Федерации за пределами территории Российской Федерации). При отсутствии документа, удостоверяющего личность, поступающий не допускается к участию на экзамене, допуск к очному вступительному испытанию поступающий получает после предъявления оригинала документа, удостоверяющего личность поступающего, представителю Приемной комиссии/дежурному по аудитории. В случае опоздания на очное вступительное испытание или в

случае задержки с подключением к дистанционному вступительному испытанию, поступающий может быть допущен к участию при условии опоздания не более 30 минут с момента начала вступительного испытания, без продления времени выполнения заданий.

Экзамен проводится в тестовой форме, очно или дистанционно с использованием системы прокторинга.

Во время проведения вступительных испытаний поступающему запрещается пользоваться учебниками, справочными материалами, тетрадями, записями, мобильными телефонами, электронными записными книжками и другими средствами хранения информации.

*Перечень знаний, умений и навыков, которыми должен обладать поступающий.*

Сдающие вступительный экзамен по татарскому языку должны:

*Знать* теоретический материал по*:*

- фонетике родного татарского языка;
- графике;
- орфографии;
- лексике и фразеологии;
- морфемике и словообразованию;
- морфологии;
- синтаксису словосочетания, предложения;
- стилистике.

*Владеть* навыками*:*

- фонетического анализа;
- графического и орфографического анализа;
- лексического анализа;
- морфемного и словообразовательного анализа;
- морфологического анализа слов разных частей речи;
- синтаксического анализа словосочетания, простого и сложных предложений разных типов.

*Уметь:*

- анализировать языковые единицы разных уровней;

-разграничивать основные единицы языка и их разновидности;

-употреблять их в соответствии с нормами литературного языка;

- анализировать языковые и лингвостилистические особенности текста.

**1.3. *Описание формы проведения вступительных испытаний***

*Форма проведения вступительного испытания* – письменный экзамен по направлению бакалавриата.

Вступительное испытание проводится очно и (или) с применением дистанционных технологий.

**1.4. *Продолжительность вступительных испытаний в минутах***

На выполнение заданий дается 120 минут. При дистанционном подключении к вступительному экзамену в течение всего экзамена абитуриенту необходимо находиться в кадре.

**1.5. *Структура вступительных испытаний***

По результатам вступительного испытания абитуриент набирает определенное количество баллов. Абитуриент решает тестовые задания состоящие из 40 вопросов. Максимальная оценка по результатам вступительного испытания составляет 100 баллов. Набравшие менее 40 баллов, выбывают из конкурса.

Экзамен позволяет проверить: уровень развития научного мышления абитуриента, знание основных вопросов теории образовательного процесса, умение самостоятельно решать профессиональные задачи разного характера и уровня сложности.

Экзаменационные задания состоят из трех блоков.

Первый блок – тесты с выбором одного правильного ответа.

Второй блок – тесты на соответствия.

Третий блок заданий предполагает ответы, которые нужно написать по определенным требованиям, которые расписываются в тексте заданий.

## Раздел 2. Содержание программы

**Тел турында гомуми мәгълүмат**

Иҗтимагый күренеш буларак тел. Тел үсеше турында гомуми мәгълүмат. Телнең структур һәм функциональ үсеше. Татар милли әдәби теленең формалашуы. Татар теленең төп диалектлары. Тел гыйлеменең әһәмияте һәм төп бүлекләре. Тел – милләтнең иң кыйммәтле тарихи ядкәре.

**Фонетика һәм орфоэпия**

Фонетика һәм орфоэпия турында төшенчә.

Сөйләм органнары. Авазларның ясалышы. Сузык һәм тартык авазлар арасында аерма.

Татар телендә сузык авазлар. Калын һәм нечкә сузыклар (арткы һәм алгы рәт сузыклары). Сингармонизм законы, аның төрләре. Сингармонизм законы сакланмаган очраклар.

Татар телендә тартык авазлар. Яңгырау һәм саңгырау тартыклар. Тел арты тартыклары һәм увуляр тартыклар. Ирен-ирен һәм ирен-теш тартыклары. Тартыкларның охшашлануы (ассимиляция). Тартыкларның чиратлашуы.

Аваз һәм хәреф. Авазларны язуда күрсәтү. Алфавит.Әйтелеш һәм язылышның туры килмәгән очраклары. ***Я, е, ю, ё*** хәрефләренең дөрес язылышы. ***О, ө, ы, е, э*** хәрефләренең дөрес язылышы. Тавышсыз хәрефләрнең дөрес язылышы.

Татар телендә иҗек һәм басым. Интонация.

**Лексика һәм сөйләм культурасы**

Лексика һәм сөйләм культурасы турында төшенчә. Татар теленең сүзлек байлыгы (лексикасы) һәм аның үзгәрүе.

Сүз. Аның мәгънәсе. Бер һәм күпмәгънәле сүзләр. Сүзләрнең туры һәм күчерелмә мәгънәләре. Омонимнар, синонимнар, антонимнар.

Кулланылыш өлкәсе ягыннан татар теленең сүзлек составы. Гомумхалык сүзләре. Әдәби тел сүзләре. Диалекталь сүзләр. Профессиональ сүзләр. Терминнар.

Кулланылыш дәрәҗәсе ягыннан татар теленең сүзлек составы. Тарихи сүзләр һәм архаизмнар. Неологизмнар. Алынмалар.

Лексикография. Сүзлекләрнең төрләре.

**Сүз төзелеше һәм ясалышы**

Сүз төзелеше. Сүзнең мәгънәле кисәкләре. Тамыр һәм кушымча. Сүз ясагыч һәм мөнәсәбәт белдерүче кушымчалар. Мөнәсәбәт белдерүче кушымчаларның модальлек һәм бәйләгеч төрләре. Аларны сүзгә ялгау тәртибе. Сүзнең нигезе.

Татар телендә сүз ясалышы ысуллары. Кушымчалар ялгап, сүз ясау. Сүзләрне кушу юлы (саф кушма сүзләр, тезмә сүзләр, кыскартылма сүзләр), аларның дөрес язылышы. Сүзләрнең аваз составын үзгәртү. Сүзләрнең мәгънәсен үзгәртү. Сүзләрнең бер сүз төркеменнән икенчесенә күчү юлы (исем фигыльнең исемгә, сыйфат фигыльнең исемгә һ.б.).

**Морфология**

Тел белеменең сүз төркеменәрен өйрәнә торган тармагы буларак морфология.

Сүз төркемнәре турында төшенчә. Татар телендә сүз төркемнәре. Сөйләм оештырудагы рольләреннән чыгып, сүзләрнең мөстәкыйль сүз төркемнәренә, бәйләгеч сүз төркемнәренә, модаль сүз төркемнәренә бүленүе.

Исем. Сүз төркеме булара кисем. Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр. Исемнәрнең берлек һәм күплек төрләре. Исемнәрнең килеш һәм тартым белән төрләнеше. Тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнеше. Сан, тартым һәм килеш кушымчаларын куллануда стилистик төрлелек. Исемнәрнең җөмләдә кулланылышы. Исемнәргә морфологик анализ ясау тәртибе.

Фигыль. Фигыль турында төшенчә. Фигыльнең башлангыч формасы. Барлык-юклык төре. Фигыльләрнең зат-сан белән төрләнеше. Фигыль юнәлешләре.

Зàтланышлы фигыльләр.

Хикәя фигыль. Хәзерге, үткән, киләчәк заман хикәя фигыльләр. Аларның мәгънәсе, ясалышы. Зат-сàн белән төрләнеше, дөрес язылышы. Җөмләдә кулланылышы.

Боерык фигыль. Аның мәгънәсе, зат-сан белән төрләнеше. Җөмләдә кулланылышы.

Шарт фигыль. Аның мәгънәсе, ясалышы, зат-сан белән төрләнеше, җөмләдә кулланылышы.

Затланышлы фигыльләргә морфологик анализ ясау тәртибе.

Затланышсыз фигыльләр.

Сыйфат фигыль. Аның мәгънәсе, ясалышы, фигыль һәм сыйфат белән уртак билгеләре. Заманнары. Исемләшүе. Үткән заман һәм киләчәк заман сыйфат фигыльләрнең хикәя фигыльләр белән охшаш һәм аермалы яклары. Сыйфат фигыльләрнең җөмләдә кулланылышы.

Хәл фигыль. Аның мәгънәсе, төрләре, ясалышы. Рәвеш һәм фигыль белән уртак билгеләре. Икенче төр хәл фигыльнең хикәя фигыль белән охшаш һәм аермалы яклары. Хәл фигыльнең җөмләдә кулланылышы.

Исем фигыль. Аның мәгънәсе, ясалышы. Исем һәм фигыль белән уртак билгеләре. Исем фигыльнең исемгә күчүе. Исем фигыльнең җөмләдә кулланылышы.

Инфинитив. Аның мәгънәсе, ясалышы, дөрес язылышы. Инфинитивның җөмләдә кулланылышы.

Ярдәмче фигыльләр һәм аларның кулланылышы. Мөстәкыйль фигыльләрнең ярдәмче фигыль мәгънәсендә йөрүе.

Затланышсыз фигыльләргә морфологик анализ ясау тәртибе.

Сыйфат. Сыйфат турында төшенчә, аның мәгънәсе, сыйфат дәрәҗәләре. Аларның ясалышы һәм дөрес язылышы. Сыйфатның исемләшүе. Сыйфатларның җөмләдә кулланылышы. Сыйфатка морфологик анализ ясау тәртибе.

Сан. Сан турында төшенчә, аның мәгънәсе. Сан төркемчәләре: төп сан, тәртип саны, бүлем саны, чама саны, җыю саны, өлеш саны. Саннарның

исемләшүе. Язуда рим һәм гарәп цифрларының кулланылышы һәм дөрес язылышы. Төзелеше буенча сан төрләре (тамыр, кушма, парлы, тезмә саннар), аларның дөрес язылышы. Санга морфологик анализ ясау тәртибе.

Рәвеш. Рәвеш турында төшенчә, аның мәгънәсе. Рәвеш төркемчәләре: саф, охшату-чагыштыру, күләм-чама, вакыт һәм урын, сәбәп-максат рәвешләре. Рәвешләрнең җөмләдә кулланылышы. Рәвешләргә морфологик анализ ясау тәртибе.

Алмашлык. Аның башка мөстәкыйль сүз төркемнәреннән аермасы. Алмашлыкларның төркемчәләре. Билгеләү, билгесезлек һәм юклык алмашлыкларының дөрес язылышы. Алмашлыкларның җөмләдә кулланылышы. Алмашлыкларга морфологик анализ ясау тәртибе.

Аваз ияртемнәре. Аваз ияртемнәренең җөмләдә кулланылышы. Аларның дөрес язылышы. Аваз ияртемнәренә морфологик анализ ясау тәртибе.

Бәйлек. Бәйлек турында гомуми төшенчә. Үзләреннән алда килгән сүзләрнең нинди килештә килүен таләп итүдән чыгып, бәйлекләрнең төркемчәләре. Бәйлекләрнең практик кулланылышы. Бәйлек сүзләр. Бәйлекләргә морфологик анализ ясау тәртибе.

Теркәгеч. Теркәгеч турында гомуми төшенчә. Теркәгечләрнең төркемчәләре: тезүче һәм ияртүче теркәгечләр. Теркәгеч сүзләр. Теркәгечләрнең дөрес язылышы. Теркәгечләрнең җөмләдә кулланылышы. Теркәгечкә морфологик анализ ясау тәртибе.

Кисәкчә. Кисәкчә турында гомуми төшенчә. Кисәкчәләрнең төркемчәләре (көчәйткеч һәм чикләүче кисәкчәләр, сорауны, раслауны, билгесезлекне, икеләнүне, теләкне, үтенүне, юклыкны белдерүче кисәкчәләр). Кисәкчәләрне сөйләмдә куллану. Кисәкчәләрнең дөрес язылышы. Кисәкчәләргә морфологик анализ ясау тәртибе.

Хәбәрлек сүзләр. Хәбәрлек сүзләрнең мөстәкыйль сүз төркемнәре белән охшаш һәм аермалы яклары. Аларның җөмләдә кулланылышы. Хәбәрлек сүзләргә морфологик анализ ясау тәртибе.

Ымлыклар. Аларның төркемчәләре. Дөрес язылышы. Ымлыкларга морфологик анализ ясау тәртибе.

**Синтаксис**

Синтаксис турында төшенчә. Төп синтаксик берәмлекләр: сүзтезмә, синтагма, җөмлә, җөмлә кисәкләре, кушма җөмлә, текст.

Гади җөмлә синтаксисы. Сүзтезмә турында төшенчә. Аның сүздән һәм җөмләдән аермасы. Ияртүче һәм иярүче кисәкләр турында төшенчә. Ияртүче кисәкнең кайсы сүз төркеменә керүенә карап, сүзтезмәләрне төркемләү.

Җөмлә турында төшенчә. Әйтү максаты буенча җөмлә төрләре: хикәя, сорау, боеру җөмләләр. Тойгылы җөмләләр. Аларны оештыруда катнашучы чаралар.

Җөмләдә сүзләр бәйләнеше. Тезүле һәм ияртүле бәйләнеш. Тезүле бәйләнешне белдерүче чаралар. Ияртүле бәйләнешне белдерүче чаралар. Ияртүле бәйләнештә торган сүзләр арасындагы мөнәсәбәтләр.

Ике составлы җөмлә турында төшенчә. Баш һәм иярчен кисәкләр. Җыйнак һәм җәенке җөмләләр

Җөмләнең баш кисәкләре.

Ия һәм аның белдерелүе.

Хәбәр һәм аның белдерелүе. Хәбәрнең ия белән ярашуы. Ия белән хәбәр арасында  сызык.

Җөмләнең иярчен кисәкләре.

Аергыч һәм аның белдерелүе. Аергычларның аерылмышы белән бәйләнеше. Тиңдәш һәм тиңдәш түгел аергычлар.

Тәмамлык һәм аның белдерелүе. Туры һәм кыек тәмамлыклар.

Хәл.Аның төркемчәләре, аларның белдерелүе.

Аныклагыч. Аның башка иярчен кисәкләрдән аермасы, белдерелүе. Аныкланмыш белән бәйләнеше.

Җөмлә кисәкләренең шартлы билгеләре.

Җөмләнең модаль кисәкләре. Эндәш сүзләр, алар янында тыныш билгеләре. Кереш сүзләр һәм кереш җөмләләр, аларның мәгънәләре, алар янында тыныш билгеләре.

Җөмләдә сүз тәртибе турында гомуми төшенчә. Җөмләдә сүзләрнең туры һәм кире тәртибе. Логик басым.

Җөмләнең аерымланган кисәкләре турында гомуми төшенчә. Аерымланган хәлләр. Аерымланган аныклагычлар. Алар янында тыныш билгеләре.

Җөмләнең тиңдәш кисәкләре турында төшенчә. Тиңдәш кисәкләрнең үзара бәйләнеше. Тиңдәш кисәкләр янында гомумиләштерүче сүзләр. Тиңдәш кисәкләр һәм гомумиләштерүче сүзләр янында тыныш билгеләре.

Тулы һәм ким җөмләләр. Ким җөмләләрнең сөйләмдә кулланылышы.

Бер составлы җөмләләр турында төшенчә. Бер составлы фигыль җөмләләр. Бер составлы исем җөмләләр.

Туры һәм кыек сөйләм. Диалог, аның язылышы, тыныш билгеләре. Туры сөйләмне кыек сөйләмгә әйләндерү.

Гади җөмләгә синтаксик анализ ясау тәртибе.

Кушма җөмлә синтаксисы. Кушма җөмлә турында гомуми төшенчә. Кушма җөмләләрне төркемләү.

Тезмә кушма җөмләләр. Аларның төрләре: теркәгечле һәм теркәгечсез тезмә кушма җөмләләр. Аларда тыныш билгеләре.

Иярченле кушма җөмләләр. Төзелеше ягыннан иярченле кушма җөмлә төрләре – аналитик һәм синтетик иярченле кушма җөмләләр. Алардагы бәйләүче чаралар. Синтетик һәм аналитик иярченле кушма җөмләләрдә тыныш билгеләре.

Иярчен җөмләләрнең мәгънә ягыннан төрләре: иярчен ия, иярчен хәбәр, иярчен аергыч, иярчен тәмамлык һәм иярчен хәл (иярчен урын, иярчен вакыт, иярчен рәвеш, иярчен күләм, иярчен сәбәп, иярчен максат, иярчен шарт, иярчен кире) җөмләләр. Аларда тыныш билгеләре.

Катлаулы синтаксик конструкцияләр турында төшенчә.

Күп иярченле кушма җөмләләр: тиңдәш иярүле, тиңдәш түгел иярүле, бер-бер артлы иярүле, берничә төр иярүле.

Катнаш кушма җөмлә, аның төзелеше, андагы тыныш билгеләре.

Кушма һәм катлаулы җөмләләргә анализ ясау тәртибе.

**Пунктуация**

Җөмләнең мәгънәсе һәм төзелеше, интонация һәм тыныш билгеләре. Нокта, сорау, өндәү билгеләре, сорау-өндәү билгеләре куела торган очраклар. Күпнокталар һәм куштырнаклар куела торган очраклар. Өтер, нокталы өтер, ике нокта куела торган очраклар. Сызык һәм җәяләр куела торган очраклар.

**Стилистика һәм сөйләм культурасы**

Әдәби тел һәм аның стильләре. Язма һәм сөйләмә стиль. Функциональ стильләр: матур әдәбият стиле, вакытлы матбугат стиле, фәнни стиль, эш кәгазьләре стиле, эпистоляр стиль.

Сөйләм культурасы һәм аның нигезләре. Сөйләмгә куела торган таләпләр.

## Раздел 3. Фонд оценочных средств

### *3.1. Инструкция по выполнению работы*

Во время проведения вступительных испытаний поступающему запрещается пользоваться учебниками, справочными материалами, тетрадями, записями, мобильными телефонами, электронными записными книжками и другими средствами хранения информации.

Задания выполняются на предоставленных бумажных носителях. Используются только шариковые ручки.

Результаты вступительных испытаний оцениваются по 100-балльной шкале.

Экзаменационные задания состоят из трех блоков.

Первый блок – тесты с выбором одного правильного ответа. Каждый правильный ответ оценивается в два балла. Всего 20 заданий, итого – 40 баллов.

Второй блок – тесты на соответствия. 10 заданий, каждый по 3 балла, итого – 30 баллов.

Третий блок заданий предполагает ответы, которые нужно написать по определенным требованиям, которые расписываются в тексте заданий. Всего 10 вопросов, оцениваются тремя баллами каждый. Итого – 30 баллов.

### *3.2. Образцы экзаменационных вопросов (тестов)*

**А. Тест.** Бирелгән 4 вариант арасыннан бер дөрес җавапны табып билгеләгез.

А1. [ә] авазын тасвирлаган билгеләмәне күрсәтегез.

1. арткы рәт, урта күтәрелешле, иренләшмәгән кыска сузык;
2. алгы рәт, урта күтәрелешле, иренләшмәгән кыска сузык;
3. алгы рәт, түбән күтәрелешле, иренләшмәгән озын сузык;
4. арткы рәт, түбән күтәрелешле, иренләшмәгән озын сузык.

А2. Яңгырау тартыклардан гына торган рәтне күрсәтегез.

1. б, г, җ, д;
2. т, в, с, й;
3. л, р, к, ф;
4. w, н, һ, щ.

А3. Нинди аваз үзгәрешенә диссимиляция диләр?

1. сузык авазларның калынлыкта-нечкәлектә ярашуы;
2. сузыкларның кыскаруы яки төшеп калуы;
3. тартык авазларның охшашлануы;
4. тартык авазларның охшашсызлануы.

А4. БОЛЫН сүзенең язылыш принцибын күрсәтегез.

1. фонетик;
2. морфологик;
3. график;
4. тарихи-традицион.

А5. “*Чакырган җиргә бар, куган җирдән кит*” мәкалендә нинди сүзләр кулланылган?

1. капма-каршы мәгънәле сүзләр;
2. мәгънәдәш сүзләр;
3. аваздаш сүзләр;
4. тамырдаш сүзләр.

А6. Фразеологизмның мәгънәсен табыгыз: КҮЗ АЧЫП ЙОМГАНЧЫ - ...

1. аптырату;
2. кыйнау;
3. тиз;
4. янау.

А7. Омофоннар булган рәтне күрсәтегез.

1. Гөлүсә – гөл үсә, искергән – ис кергән;
2. Басма – басма, сабын – сабын;
3. Төш – төш, ял – ял;
4. Тир – тир, карта - карта.

А8. Җөмләдә аерып бирелгән диалектизмның мәгънәсен билгеләгез: “*Әйдәгез, ҖӘРЕНГӘ болынны терелтәбез*” (Н.Гыйматдинова).

1. иртәгә;
2. киләсе елга;
3. җәйгә;
4. быел.

А9. Сүзнең тамыры дип нәрсәгә әйтәләр?

1. сүзнең мәгънәгә ия иң кечкенә кисәге;
2. сүзнең төп мәгънәсен белдерә торган кисәге;
3. сүзнең төрләндергеч кушымчаларын алганнан соң калган өлеше;

4. сүзгә яңа мәгънә өсти торган кисәк.

A10. Тезмә сүзне күрсәтегез.
1. аш[...]казаны;
2. җил[...]тегермәне;
3. савыт[...]саба;
4. җете[...]кызыл.

A11. Фигыль ясагыч кушымчалардан торган рәтне билгеләгез.
1. -чы/че, -даш/-дәш, -ак/-әк;
2. -лы/-ле, -гы/ге, -чан/чән;
3. -ла/-лә, -ылда/-елдә, -а/-ә;
4. -ча/-чә, -дай/-дәй, -лата/-ләтә.

A12. Сүз мәгънәле кисәкләргә дөрес аерылган очракны табыгыз.
1. кил-әчә(к)г-ем-не;
2. килә-чәгем-не;
3. ки-лә-чә-гем-не;
4. кил-әчәгем-не.

A13. Сорау алмашлыгы кергән җөмләне табыгыз.
1. Җир йөзендәге бөтен малайларның исемнәре була (Г.Мөхәммәтшин).
2. Күңелгә әллә нинди шикләр килә. (М.Әмир)
3. Бу ямьсез песине нигә керттегез? (Ә.Бикчәнтәева)
4. Кызганычка каршы, моның сәбәбен ачыклый алмадылар (Һ.Такташ)

A14. Бүлем саннары нинди кушымчалар ярдәмендә ясала?
1. -ар/-әр//-шар/-шәр;
2. -ау/-әү;
3. -нчы/-нче//-ынчы/-енче;
4. -лап/-ләп// -ларча/-ләрчә.

A15. Үзләреннән алда килгән исемнең баш килештә булуын таләп иткән бәйлекләр рәтен табыгыз.
1. белән, өчен, шикелле;
2. соң, бүтән, тыш;
3. таба, күрә, каршы;
4. элек, башка, бирле.

A16. Сыйфат кергән җөмләне табыгыз.

1. Дүрт яктан дошман булса да, һәрбер адымны тик сугышып кына атласак та, күңелем ышанадыр иде: кайдадыр яктылык бар, кайчан да булса без шуңа ирешербез, ди идек. (Г.Ибраһимов);

2. Тау түбәсеннән берәү ат чаптырып бара – ул, әкият батырыдай, дөрләп янган ут эченә ташланды (М.Хәбибуллин);

3. Җиләк җыю буенча балалар арасында Мәрфуга карчыктан кала иң зур абруй Зөлфиядә иде (М.Мәһдиев);

4. Әнә ике кыз койрыкның иң очына утырганнар да пароход артыннан ургылып калган суга карап баралар (Ә.Еники).

А17. Рәвешле исем сүзтезмәне табыгыз.

1. күп китап;
2. яңа йорт;
3. дуслардан бишәү;
4. икенче дусты.

А18. “*Көннәрдән беркөнне ул кабак юкка чыкты”(Ф.Хөсни)* җөмләсендә УЛ сүзе нинди җөмлә кисәге була?

1. хәбәр;
2. тәмамлык;
3. ия;
4. аергыч.

А19. Тиңдәш түгел иярүле күп иярченле кушма җөмләгә туры килгән билгеләмәне табыгыз.

1. Мондый җөмләләрдә иярчен җөмләләр баш җөмләнең бер үк кисәген бер үк яктан ачыклыйлар.

2. Мондый җөмләләрдә иярчен җөмләләр баш җөмләне төрле яктан ачыклыйлар.

3. Мондый җөмләләрдә иярчен җөмләләр баш җөмләгә бер-бер артлы ияреләр.

4. Мондый җөмләләрдә иярчен җөмләләр баш җөмләгә карата төрле бәйләнеш комбинацияләрендә киләләр.

А20. Төрле сәбәпләр аркасында сөйләмнең әйтелеп бетмәвен күрсәтү өчен _______________ куела.

1. күпнокта;
2. сызык;
3. җәяләр;
4. өтер.

В1. Тәңгәллекләр урнаштырыгыз. Җавапта саннар җыелмасын буш аралык калдырмыйча һәм тыныш билгеләрсез языгыз.

| | |
|---|---|
| А) [у] | 1) арткы рәт, иренләшкән, урта күтәрелешле сузык аваз |
| Б) [а] | 2) арткы рәт, иренләшмәгән, урта күтәрелешле сузык аваз |
| В) [о] | 3) арткы рәт, иренләшмәгән, түбән күтәрелешле сузык аваз |
| Г) [ы] | 4) арткы рәт, иренләшкән, югары күтәрелешле сузык аваз |

В2. Тәңгәллекләр урнаштырыгыз. Җавапта саннар җыелмасын буш аралык калдырмыйча һәм тыныш билгеләрсез языгыз.

| | |
|---|---|
| А) ихтимал | 1) басым сүзнең беренче иҗегенә төшә |
| Б) кирәкми | 2) басым сүзнең икенче иҗегенә төшә |
| В) күтәренке | 3) басым сүзнең өченче иҗегенә төшә |
| Г) мөгаен | 4) басым сүзнең дүртенче иҗегенә төшә |

В3. Тәңгәллекләр урнаштырыгыз. Җавапта саннар җыелмасын буш аралык калдырмыйча һәм тыныш билгеләрсез языгыз.

| | |
|---|---|
| А) бөркә | 1) сүз ясагыч кушымча ялгану ысулы белән ясалган сүз |
| Б) бөркүлек | 2) сүзләр кушылу ысулы белән ясалган сүз |
| В) бөкре | 3) конверсия ысулы белән ясалган сүз |
| Г) билбау | 4) тамыр сүз |

В4. Тәңгәллекләр урнаштырыгыз. Җавапта саннар җыелмасын буш аралык калдырмыйча һәм тыныш билгеләрсез языгыз.

| | |
|---|---|
| А) матча | 1) составында сүз ясагыч кушымча булган сүз |
| Б) мәйданчык | 2) составында бернинди дә кушымча булмаган тамыр сүз |
| В) мүкләгәч | 3) составында бәйләгеч кушымча булган сүз |
| Г) мыекча | 4) составында модальлек кушымчасы булган сүз |

В5. Тәңгәллекләр урнаштырыгыз. Җавапта саннар җыелмасын буш аралык калдырмыйча һәм тыныш билгеләрсез языгыз.

| | |
|---|---|
| А) авызы пешкән | 1) ягымлы сүзле кеше |
| Б) бал авыз | 2) исеме чыгу |
| В) дан китү | 3) буйсындыра алмау |
| Г) йөгәннән ычкындыру | 4) алданган кеше |

В6. Тәңгәллекләр урнаштырыгыз. Җавапта саннар җыелмасын буш аралык калдырмыйча һәм тыныш билгеләрсез языгыз.

| | |
|---|---|
| А) холык, табигать | 1) антонимнар |
| Б) карсак, озын | 2) синонимнар |
| В) кызарган, кыз арган | 3) паронимнар |

| | |
|---|---|
| Г) диктант, диктат | 4) омонимнар |

В7. Тәңгәллекләр урнаштырыгыз. Җавапта саннар җыелмасын буш аралык калдырмыйча һәм тыныш билгеләрсез языгыз.

| | |
|---|---|
| А) Солтангәрәй бөтен күңелен укуга бирде. | 1) составында иялек килешендәге зат алмашлыгы булган җөмлә |
| Б) Бу эшкә аның кулы килешеп тора иде. | 2) составында вакыт рәвеше булган җөмлә |
| В) Без хәзер һөнәрле. | 3) составында тамыр сыйфат булган җөмлә |
| Г) Замананың көе үзгә шул. | 4) составында төшем килешендәге исем булган җөмлә |

В8. Тәңгәллекләр урнаштырыгыз. Җавапта саннар җыелмасын буш аралык калдырмыйча һәм тыныш билгеләрсез языгыз.

| | |
|---|---|
| А) предметның, затның билгесен белдерә торган мөстәкыйль сүз төркеме | 1) алмашлык |
| Б) предметны һәм затны белдерә торган мөстәкыйль сүз төркеме | 2) исем |
| В) исемне, сыйфатны, санны һәм рәвешне алмаштырып килә торган мөстәкыйль сүз төркеме | 3) рәвеш |
| Г) эш яки хәлнең билгесен белдерә торган мөстәкыйль сүз төркеме | 4) сыйфат |

В9. Тәңгәллекләр урнаштырыгыз. Җавапта саннар җыелмасын буш аралык калдырмыйча һәм тыныш билгеләрсез языгыз.

| | |
|---|---|
| А) Җиде кат үлчә, бер кат кис. | 1) составында урын хәле булган җөмлә |
| Б) Ул монда артык кеше иде. | 2) составында вакыт хәле булган җөмлә |
| В) Ул моны сиздермәс өчен елмайган булды. | 3) составында максат хәле булган җөмлә |
| Г) Кичен мин аны озатып калдым. | 4) составында күләм хәле булган җөмлә |

В10. Тәңгәллекләр урнаштырыгыз. Җавапта саннар җыелмасын буш аралык калдырмыйча һәм тыныш билгеләрсез языгыз.

| | |
|---|---|
| А) Зөфәр болай әйбәт кеше иде, дөресрәге, ул үзен иң уңай яктан күрсәтә белә иде. (Ә.Еники) | 1) иярчен аергыч җөмлә |
| Б) Ләкин безгә алар белән танышырга туры килмәде, чөнки без анда өч-дүрт көн генә тордык. (Ш.Камал) | 2) иярчен рәвеш җөмлә |
| В) Ул биргән ак яулык та озак еллар түш кесәсеннән төшмәде. (Ш.Маннур) | 3) иярчен сәбәп җөмлә |

| | |
|---|---|
| Г) Ул, күзләре еракка текәлгән килеш, туган ил табигатенә сокланып торды. (М.Әмир) | 4) иярчен аныклагыч җөмлә |

В11. “*Кулың җиткән ботакның җимешен өз”* (Мәкаль) җөмләсендә ТСТ калыбына туры килгән ничә иҗек бар?

**Җавапны сан белән языгыз.**

В12. “*Эченә салмасаң, тышына чыкмас”* (Мәкаль) җөмләсендә сүз басымы соңгы иҗеккә төшмәгән ничә сүз бар?

**Җавапны сан белән языгыз.**

В13. Бирелгән рәттә ничә сүз артык: *күренекле, уңган, атаклы, танылган, эшлекле, тырыш, мәшһүр, атказанган*

**Җавапны сан белән языгыз.**

В14. “*Төп ... утырту”* фразеологик әйтелмәсендә нокталар урынында кайсы сүз төшеп калган?

**Җавап сүзне баш хәрефләр белән фразеологизмда кулланылган формада языгыз.**

В15. “*Кош – канаты белән, гаилә татулыгы белән көчле”* (Мәкаль) җөмләсендә ничә ясалма сүз бар?

**Җавапны сан белән языгыз.**

В16. “*Баш белән таш ярып булмый”* (Мәкаль) җөмләсендәге БЕЛӘН сүзе кайсы сүз төркеменә карый?

**Җавап сүзне (терминны) баш хәрефләр белән берлек санда языгыз.**

В17. “*Уйламыйча башлама, башлаган эшне ташлама”* (Мәкаль) җөмләсендә ничә затланышсыз фигыль кулланылган?

**Җавапны сан белән языгыз.**

В18. *Начар арба юл боза* (Мәкаль) җөмләсендәге ЮЛ сүзе нинди җөмлә кисәге?

**Җавап сүзне (терминны) баш хәрефләр белән баш килештә, берлек санда языгыз.**

В19. “*Болында үлән ни хәтле, анда кеше шул хәтле”* (Г.Бәширов ) җөмләсендә аналитик иярчен компонентның мәгънәви төре нинди?

**Җавап сүзне (бер сүз) баш хәрефләр белән языгыз.**

В20. “*Дала буш, дала тын, үзе тип-тигез һәм очсыз-кырыйсыз”* (Ә.Еники) җөмләсе ничә компоненттан тора?

**Җавапны сан белән языгыз.**

## Раздел 4. Список литературы

**(**Перечень литературы и информационных источников для подготовки к вступительным испытаниям**)**

**а) основная**

1. Галиуллина Г.Р., Шәкүрова М.М. Татар телендә гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәпләре өчен ана теленнән программа (5-9 нчы сыйныфлар). http://mon.tatarstan.ru/rus/file / pub / pub_263448. docx.

2. Зәкиев М.З. Татар теле: Татар урта гомуми белем мәкт. 8 нче с-фы өчен д-лек. – 3 нче басма. – Казан: Мәгариф, 2002. – 159 б.

3. Зәкиев М.З. Татар теле: Татар урта гомуми белем мәкт. 9 нчы с-фы өчен д-лек. / М.З.Зәкиев, С.М.Ибраһимов. – Тулыл. 4 нче басма. – Казан: Мәгариф, 2008. – 159 б.

4. Зәкиев М.З., Максимов Н.В. Татар теле: Татар урта гомуми белем бирү мәкт. 10–11 нче с-флары өчен д-лек. Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. – 334 б.

5. Максимов Н.В. Татар теле. 7 сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы / Н.В. Максимов, Г.Ә. Нәбиуллина. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 159 б.

6. Мирзаһитов Р.Х. Татар теле. 9 сыйныф: рус телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Р.Х. Мирзаһитов, М.М. Шәкүрова, Н.Х. Мусаяпова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2017. – 190 б.

7. Сәгъдиева Р.К. Татар теле: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). 6 нчы с-ф. / Р.К. Сәгъдиева, Р.М. Гарәпшина, Г.И. Хәйруллина. – Казан: «Мәгариф–Вакыт» нәшр., 2015. – 191 б.

8. Сәгъдиева Р.К. Татар теле: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). 7 нче с-ф. / Р.К. Сәгъдиева, Г.Ф. Харисова, Л.К. Сабирҗанова, М.Ә. Нуриева. – Казан: «Мәгариф–Вакыт» нәшр., 2015. – 215 б.

9. Сәгъдиева Р.К. Татар теле: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). 8 нче с-ф. / Р.К. Сәгъдиева, Г.И. Хәйруллина. – Казан: «Мәгариф–Вакыт» нәшр., 2016. – 223 б.

10. Сәгъдиева Р.К. Татар теле: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). 9 нчы с-ф. / Р.К. Сәгъдиева, Э.Х. Кадирова. – Казан: «Мәгариф–Вакыт» нәшр., 2016. – 143 б.

11. Сәгъдиева Р.К., Хөснетдинов Д.Х. Татар теленнән презентацияләр. 664 слайд. – Казан: «Мәгариф–Вакыт» нәшр., 2016. (диск)

12. Татар теле (кагыйдәләр, методик киңәшләр, анализ үрнәкләре, биремнәр). Абитуриентлар, укытучылар, студентлар өчен. / Мирзаһитов Р.Х., Сәгъдиева Р.К., Хөснетдинов Д.Х. – Казан: «Мәгариф–Вакыт» нәшр., 2017. – 191 б.

13. Татар теле. 8 сыйныф: рус телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Ф. Гайнуллина һ.б. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. – 182 б.

14. Харисов Ф.Ф., Харисова Ч.М. Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына татар теле: үрнәк гомуми программа (V–IX сыйныфлар). http://mon.tatarstan.ru/rus/programmy.htm?page=2

15. Харисов Ф.Ф., Харисова Ч.М. Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына татар теле: үрнәк гомуми программа (X–XI сыйныфлар). http://mon.tatarstan.ru/rus/programmy.htm?page=2

16. Харисов Ф.Ф. Татар теле. 5 сыйныф: рус телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Ф.Ф. Харисов, Ч.М. Харисова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – 159 б.

17. Харисов Ф.Ф., Харисова Ч.М. Татар теленнән күнегүләр һәм тестлар. – Казан: Яңалиф, 2006.

18. Харисова Ч.М. Татар теле. 5 сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы / Ч.М. Харисова, Н.В. Максимов, Р.Р. Сәйфетдинов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – 207 б.

19. Харисова Ч.М. Татар теле. Анализ үрнәкләре: Югары сыйныф укучылары, абитуриентлар, студентлар, укытучылар өчен ярдәмлек / Ч.М. Харисова. – Казан: Мәгариф, 2009. – 119 б.

20. Хәсәншина Р.Г. Татар теле. 5 сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы / Р.Г. Хәсәншина. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – 175 б.

21. Шәмсетдинова Р.Р. Татар теле: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) 5 нче с-ф. / Р.Р. Шәмсетдинова, Г.К. Һадиева, Г.В. Һадиева. – Казан: “Мәгариф-Вакыт” нәшр., 2015. – 175 б.

22. Юсупов Ф.Ю. Татар теле. 6 сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы / Ф.Ю. Юсупов, Ч.М. Харисова, Р.Р. Сәйфетдинов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 175 б.

**б) дополнительная**

1. Абдуллина Р.С. Сөйләм культурасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2012.

2. Сафиуллина Ф.С., Ибраһимов С.М., Вафина Э.Х. Хәзерге татар телендә тыныш билгеләре. – Казан, ТКН, 1995.

3. Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле. Югары уку йортларының әзерлек факультетлары һәм абитуриентлар өчен дәреслек. – Казан университеты нәшрияты, 2002.

**в) словари и справочники**

1. Исәнбәт Н.С. Татар теленең фразеологик сүзлеге: 2 томда. – Т. II / Н.С.Исәнбәт. – Казан: Татар. кит. нәшр.,1990. – 368 б.

2. Исәнбәт Н.С. Татар теленең фразеологик сүзлеге: 2 томда. – Т.I / Н.С.Исәнбәт. – Казан: Татар.кит. нәшр.,1989. – 495 б.

3. Русско-татарский толковый словарь лингвистических терминов / под ред. Ф.И. Тагировой и Ф.Ф. Гаффаровой. – Казан: ИЯЛИ, 2016. –248 с.

4. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге / ред. Ф.Ф. Гаффарова, Ф.И. Таһирова, Р.Т. Сәфәров. –Казань: ТӘhСИ, 2017. –Т. 3: К. –744 с.

5. Татар теленең орфографик сүзлеге. – Казан, «Раннур», 2002.

6. Татар теленең этимологик сүзлеге: 2 томда / төз. Р.Г. Әхмәтьянов; фәннимөхәррире Р.Т. Сәфәров. –Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015.